ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.12.2019 Казан шәһәре № 7-13/т

Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә даими пассажирлар йөртүнең муниципаль маршрутлары буенча автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында даими рәвештә пассажирлар һәм багаж йөртүгә чик дәрәҗәдә максималь тарифлар билгеләү турында

«Автомобиль транспорты һәм җир өсте шәһәр электр транспорты уставы» 2007 елның 8 ноябрендәге 259-ФЗ номерлы һәм «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында даими рәвештә пассажирлар һәм багаж йөртүне оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бәяләрне (тарифларны) дәүләти җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 7 мартындагы 239 номерлы карары, «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында даими рәвештә пассажирлар һәм багаж йөртүне оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» федераль законны тормышка ашыру хакында» 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карар кушымтасы нигезендә Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә даими пассажирлар йөртүнең муниципаль маршрутлары буенча автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында даими рәвештә пассажирлар һәм багаж йөртүгә чик дәрәҗәдә максималь тарифлар билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә даими пассажирлар йөртүнең муниципаль маршрутлары буенча автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында даими рәвештә пассажирлар һәм багаж йөртүгә чик дәрәҗәдә максималь тарифлар билгеләү турында» 29.12.2018 № 7-12/т карарының 1.1 пунктын гамәлдән чыккан дип танырга.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 20.12.2019 № 7-13/т карарына кушымта

Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә даими пассажирлар йөртүнең муниципаль маршрутлары буенча автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында даими рәвештә пассажирлар һәм багаж йөртүгә чик дәрәҗәдә максималь тарифлар

| Транспорт төре | Бер мәртәбә бару һәм бер урынга исәпләнгән багажны алып бару өчен чик дәрәҗәдәге максималь тарифлар (сум) | | |
|---|---|---|---|
| | билетны транспорт чарасы салонында сатып алганда | юл өчен озак файдаланыла торган билет ярдәмендә түләгәндә | |
| | | 1 мәртәбә барган өчен[1] | 100 мәртәбә барган өчен[2] |
| Автобус | 30 | 27 | 20 |
| Троллейбус | 30 | 27 | 20 |
| Трамвай | 30 | 27 | 20 |

<1> юлга билгеләнгән сумма чикләрендә бару хокукын бирә торган, озак файдаланылышлы билет белән түләгәндә;

<2> юлга билгеләнгән вакыт эчендә билгеләнгән санда бару хокукын бирә торган, озак файдаланылышлы билет белән түләгәндә.

Искәрмә. Багаж алып бару бәясен түләү юл бәясен түләүдән аерым гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге